**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ САРДЕКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СӘРДЕКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**422126, с.Сардек-Баш , Ул.Центральная , д.45 Тел./факс: (884364) 25-0-43** e-mail: Sard.Kuk@tatar.ru,

# КАРАР

«15» апрель, 2025 ел. №8

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун ел вакытка расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 19 апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән (kukmor.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә түбәндәге адресларда урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

Сәрдекбаш ав., Үзәк ур., 45 й. (административ бина);
Яңа Сәрдек ав., Яңа ур., 2а й. (авыл клубы бинасы).
Тырыш ав., Яр буе ур., 3 й. (авыл клубы бинасы).
Каенлык ав., Каенлы ур., 19 й. (авыл клубы бинасы).

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Җирлек башлыгы: И.М. Набиев

ОГРН 1021607752858
ИНН 1623001854
СОВЕТ САРДЕКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СӘРДЕКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2025 елның 15 апрелендәге 8 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы**

**1 номерлы Нижний сайлау округы.**
Сайлаучылар саны - 102.
Сайлау округына Уразай авылы, Үзәк урамның 1 - 23 нче йортлары; Яңа ур., Түбән ур., Болын урамы территорияләре керә

**2 номерлы Яр буе сайлау округы.**
Сайлаучылар саны - 101.
Сайлау округына Уразай авылы, Үзәк урамның 24 - 51 нче йортлары, Югары ур., Яр буе урамы территорияләре керә.

**3 номерлы Үзәк сайлау округы**
Сайлаучылар саны - 92.
Сайлау округына Сәрдекбаш авылы, Яңа ур., Үзәк урам территорияләре керә.

**4 номерлы Мәскәү сайлау округы**
Сайлаучылар саны - 92
Сайлау округына Сәрдекбаш авылы, Мәскәү урамының барлык йортлары керә.

**5 номерлы Каенлы сайлау округы**
Сайлаучылар саны - 84
Сайлау округына Каенлык авылы, Каенлы урамының барлык йортлары керә.

**6 номерлы Яңа сайлау округы**
Сайлаучылар саны - 86.
Сайлау округына Тырыш авылының Октябрь ур., Яңа ур. территорияләре керә.

**7 номерлы Совет сайлау округы**
Сайлаучылар саны - 100.
Сайлау округына Тырыш авылының Совет урамы территориясе керә.

**8 номерлы Яшел сайлау округы**
Сайлаучылар саны - 89.

Сайлау округына Бакчасарай поселогы, Яшел ур., Яңа ур., Югары Китәк ав., Югары урам территорияләре керә.

**9 номерлы Мәктәп сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 98.

Сайлау округына Яңа Сәрдек авылы, Үзәк урамның 5 - 10 нчы йортлары (җөп як), Үзәк урамның 7 - 33 нче йортлары (так як), Яңа урам территорияләре керә.


**10 номерлы Болын сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 86.

Сайлау округына Яңа Сәрдек авылы, Үзәк урамның 35 - 89 нсы йортлары (так як), Үзәк урамның 14 - 28 нче йортлары (җөп як) территорияләре керә.

Барлыгы 930 сайлаучы.

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәте**




| | |
|---|---|
| №1 | Түбән |
| №2 | Яр буе |
| №3 | Үзәк |
| №4 | Мәскәү |
| №5 | Каенлы |
| №6 | Яңа |
| №7 | Совет |
| №8 | Яшел |
| №9 | Мәктәп |
| №10 | Болын |